КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 август г.Казань № 961

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм эшкәртүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) агроконтракт – эшкәртүче белән шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан арасында төзәлә торган, әлеге шартнамәдә (килешүдә) карала торган шартлар нигезендә тәэмин ителә торган ачык грунт яшелчәләре, бәрәңге, сөт, ит өчен эшкәртүче тарафыннан әлеге граждан файдасына яшелчәләрнең, бәрәңгенең орлык материалын, шулай ук мөгезле эре терлек, сарык һәм кәҗәләрне тапшыру карала торган шартнамә (килешү);»;

15 пунктта:

егерме икенче абзацта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

егерме дүртенче абзацта татар текстында «хисап финанс елының IV кварталы өчен хисап елыннан соң килә торган елның беренче ярты еллыгында гамәлгә ашырылырга мөмкин» сүзләреннән соң «, әгәр бу чыгымнар элегрәк капланмаган булса» сүзләрен өстәргә;

утызынчы абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Чыгымнарны каплау финанс арендасы шартнамәсенең (лизинг шартнамәсенең) гамәлдә булу срогы дәвамында фактта кертелгән түләүләр өчен гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Акча эшкәртүчеләргә, түбәндәге шартларны исәпкә алып, әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә:

хисап финанс елының IV квартал өчен эшкәртүчеләрнең шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау хисап елыннан соң килә торган елның беренче ярты еллыгында гамәлгә ашырылырга мөмкин, әгәр бу чыгымнар элегрәк капланмаган булса;

эшкәртүчеләрнең шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау агымдагы финанс елының берничә кварталы өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин, әгәр бу чыгымнар элегрәк капланмаган булса;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» һәм «ж» пунктчаларында каралган эшкәртүчеләрнең чыгымнарын дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре исәбеннән каплау рөхсәт ителми;

җиләк-җимеш продукциясе һәм бәрәңге җыюны, аларны беренчел һәм (яки) аннан соң эшкәртүне, саклауны һәм сатуны гамәлгә ашыручы эшкәртүчеләрнең әлеге Тәртиптәге 1 пунктның «е» һәм «ж» пунктчаларында каралган чыгымнарын каплау өстәнлекле тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерүне арттыруны стимуллау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктның дүртенче абзацына «(шул ук вакытта светодиодлы фитонурландыргычларны файдаланганда өстәмә яктырту куәтенә карата таләпләр кулланылмый)» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның икенче абзацында «яшелчә культуралары өчен ГОСТ 32592-2013, ГОСТ Р 30106-94» сүзләреннән соң «, ГОСТ 32917-2014» сүзләрен өстәргә;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 1 июльгә карата субсидия бирелгән елда бәрәңге өчен чәчү мәйданы тәшкил итте, гектар;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 1 июльгә карата субсидия бирелгән елда ачык грунт яшелчәләре өчен чәчү мәйданы тәшкил итте, гектар;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 31 декабрьгә карата субсидия бирелгән елда элиталы һәм (яки) оригиналь орлык бәрәңгече чәчү күләменә ирешелде, тонна;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 31 декабрьгә карата субсидия бирелгән елда, өстәмә яктырту технологиясен кулланып, үстерелгән, үз җитештерүендә булган ябык грунт яшелчәчелек продукциясе җитештерелде, тонна;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 31 декабрьгә карата субсидия бирелгән елда бәрәңге җитештерелде, тонна;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – 31 декабрьгә карата субсидия бирелгән елында ачык грунт яшелчәләре җитештерелде, тонна.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин